ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2025 г.Лениногорск № 1009

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «2025 – 2030 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында «Актив озак яшәү» муниципаль программасын раслау турында» 2025 елның 24 июненедәге 500 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән, халык арасында сәламәт яшәү рәвешен булдыру максатларында, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.»Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «2025 – 2030 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында «Актив озак яшәү» муниципаль программасын раслау турында» 2025 елның 24 июненедәге 500 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 3 пунктны өстәргә:

«3. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Финанс-бюджет палатасы» МКУ муниципаль программаның 1 пунктында каралган чараларын гамәлгә ашыру өчен Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан акчалар эзләргә.»;

карарның 3 һәм 4 пунктларын 4 һәм 5 пунктлар дип санарга.

2. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «2025 – 2030 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында «Актив озак яшәү» муниципаль программасын раслау турында» 2025 елның 24 июнендәге 500 номерлы карары белән расланган 2025 – 2030 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында «Актив озак яшәү» муниципаль программасына (комплекслы планына) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында кушымтада бирелә торган «Актив озак яшәү» муниципаль программасы чараларын гамәлгә ашыру максатларында финанслау күләме 2025 – 2030 елларга җирле бюджеттан 7 млн. 550 мең сум тәшкил итә, шулардан:

2025 елда 1 млн. 510 мең сум
2026 ел 1 млн. 510 мең сум
2027 ел 1 млн. 510 мең сум
2028 ел 1 млн. 510 мең сум
2029 ел 1 млн. 510 мең сум
2030 ел 1 млн. 510 мең сум

Финанслау күләмнәре фаразлау характерында була һәм бюджет мөмкинлекләреннән чыгып, билгеләнгән тәртиптә ел саен төзәтелергә тиеш.

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3.1. Программада төп катнашучылар:
Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» МБ БК «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм идарәсе» МКУ;
ТР «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Мәдәният идарәсе» МКУ;
Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Мәдәният сарае» МБУ;
ТР «Лениногорск муниципаль районы» МБ БК «Мәгариф идарәсе» МКУ;
Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» МБ БК Гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге;
Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы буенча идарәсе (килешү буенча);
Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районындагы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр буенча оператив чаралар күрү бүлеге (килешү буенча);
Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Лениногорск муниципаль районындагы «Исток-Башлангыч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт учреждениесе, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы(килешү буенча);
Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча);
Татарстан Республикасы Лениногорск районында РФ пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының ТР бүлекчәсенең клиент хезмәте (килешү буенча);
«Россия пенсионерлары берлеге» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы буенча бүлеге (килешү буенча);
Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы буенча

ветераннар советының региональ иҗтимагый оешмасы (килешү буенча);

Территориаль иҗтимагый үзидарәләр (ТИҮ) (килешү буенча).

3. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында «Актив озак яшәү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру чаралары планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Җаваплы башкаручылар» баганасында сүзләрдән соң:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Лениногорск муниципаль районындагы «Исток-Башлангыч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт учреждениесе «килешү буенча» сүзләрен өстәргә;

«Долголетие» ЦСП АНО «килешү буенча»сүзләрен өстәргә;

«Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәренең сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы» МИО «килешү буенча»сүзләрен өстәргә;

«Территориаль иҗтимагый үзидарәләр (ТИҮ)» «килешү буенча»сүзләрен өстәргә;

«Лениногорск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ «килешү буенча» сүзләрен өстәргә;

«Лениногорск ДИПИ» ДАСЯО «килешү буенча» сүзләрен өстәргә;

«Медсанчасть, Шөгер хастаханәсе», «Долголетие» «ЦСП АНО» «килешү буенча» сүзләре белән тулыландырырга;

«Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ «килешү буенча» сүзләрен өстәргә.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча:https://Leninogorsk.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча:https://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И.Г.Шәмәрданов

Г.К.Урманова
5-13-80